| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2023 Балык Бистәсе штп. № 55пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елда балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 07.12.2022 №364пи карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 ел, №248-ФЗ, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 30.03.1999 ел, №52-ФЗ Федераль законнар нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елда балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 07.12.2022 №364пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 пунктның 5.1) пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.1) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 ел, № 248-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьлар сменаларын, хезмәт һәм ял лагерьлары сменаларын уздыру вакытында санитар-эпидемиологик күзәтү;».

1.2. 5.2) һәм 5.3) пунктчаларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов